**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы**
**7 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың алты биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 150 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **40.** Уңышлар!

**1. Татар халык җырларының кайсы төре турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- алар бию вакытында, күңел ачканда җырлап яки тиз ритм белән әйтелә;
- мондый җырларның бер өлешендә дустыңнан яратып көлү, аны үчекләү, шаяру яки аның билгеле бер сыйфатын мактау чагылыш таба;
- элек алар үзенә күрә уен коралы, гармун вазифасын да үтәгән.

**Җавап**: такмаклар

**2. Татарстан гимнының авторларын атагыз. (1 балл)**

а) Салих Сәйдәшев, Рамазан Байтимеров

ә) Салих Сәйдәшев, Равил Фәйзуллин

б) Рөстәм Яхин, Рамазан Байтимеров

**Җавап:**

б) Рөстәм Яхин, Рамазан Байтимеров

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

**Җавап:** Шәүкәт Галиев

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылы

ә) Башкортстанның  Бишбүләк районы Ает авылы

б) Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылы

в) Мордовия Республикасы Пешлә авылы

**Җавап:** б) Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылы

**3. Әлеге әдипнең әсәрләре генә кергән рәтне күрсәтегез. (2 балл)**

а) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Матурлык минем белән», «Һәркем әйтә дөресен».

ә) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Атлап чыктым Иделне», «Тагын бер “рәхмәт”».

б) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Кызыл ромашка», «Һәркем әйтә дөресен».

в) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Тагын бер “рәхмәт”», «Сез иң гүзәл кеше икәнсез».

**Җавап:** ә) «Шәвәли», «Пәрәмәч», «Атлап чыктым Иделне», «Тагын бер “рәхмәт”».

**4. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын билгеләгез. (6 балл)**

а) Ай, йолдызлар, күк, Чуртан, Айсылу, тап.

**Җавап:** Ф. Яруллин “Зәңгәр күлдә Ай коена”

ә) Мәгарә, кимия, симия, ихфа, Мисыр, хәлвә, патша кызы, казый.

**Җавап**: К. Насыйри “Әбүгалисина”

б) Колын, чабышкы аты, Сабан туе, мәйдан, ат чабышы, Ялгыз каен, камчы.

**Җавап:** Г. Ибраһимов “Алмачуар”

**5. а) Хикәядән өзек укыгыз.**

...Ахшам үтте. Буранның котыруына карамыйча, капкадан йөри иделәр... Хатыннар берсе килеп кергәндә, икенчесе бик кайгылы кыяфәттә чыгып бара һәм күңелсез генә берәр сүз катыша иделәр...

Тәрәзә янында яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, килгәнне каршы ала, киткәнне моңлы күзләре белән озата иде. Ул гүя кайгылы иде... Аның сөйгән тәрбиячесе – хуҗа хатын – бу кич инде үлемнең куркынычлы тырнаклары арасында сугыла иде...

Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый. Бичара хатынның өлеше бетеп килә иде...

Илле ел тәнен, уен идарә иткән җан, үзенең иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән кемгәдер актык мәртәбә карап, тынычланып китәсе килә иде. Бичара хатын күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми, торып-торып:

– Килмәдеме?.. – дип сорый иде.

Кызы Фатыйма бертуктамый елый.

**б) Сорауларга җавап бирегез.**

**1) Әсәрнең исеме (2 балл)  Җавап:** “Буранда”

**2) Әсәрнең авторы (2 балл) Җавап:** Шәриф Камал

**3) Өзектә сүз кем турында бара? (1 балл) Җавап:** ана турында

**4) Ул нинди хисләр кичерә? Ни өчен? (2 балла) Җавап:** юксыну, өзгәләнү, борчылу. Ул улын көтә.

**5) Өзектән**

- **чагыштыруга мисаллар китерегез (3 балл)**

**Җавап:** эт, гүя кайгылы иде; төсе балавыз кебек саргайган; иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән.

- **метафорага мисал табып языгыз (1 балл)**

**Җавап**: үлемнең куркынычлы тырнаклары

**6. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны таныրлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 8-10 җөмлә. (15 балл)**